وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№11 (180). 15 март 2013 / 3-җөмәдиәләүвәл-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Гатаулла БАЯЗИТОВ ▷2◁



Сәрвәретдин бине Мифтахетдин ▷3-4◁



Авылдашым, булдырасың! ▷4◁

## Аллаһ сабыр кешеләр белән бергә

*"Ий, иман китергән адәмнәр, сабыр-түзем булып, намаз укып, Аллаһтан ярдәм сорагыз. Хактыр ки, Аллаһ сабыр кешеләр белән бергә" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 153 нче аяте).*

Хәзерге заманда сабырлык кимчелек, хәтта көчсезлек буларак та кабул ителә. Сабыр кешеләрне мыскыл итәргә дә күп уйлап тормыйлар. Дөрестән дә, беренче карашка кемнеңдер сабыр итүе аның көчсезлеге булып күренергә мөмкин. Ләкин сабырлыкка ислам дине күзлегеннән карыйк әле. Сабырлык - тормышта очраган авырлыкларга түземлек күрсәтү һәм яхшы үзгәрешләр өмет итү ул. Сабыр кеше зарланмый, кычкырмый, җан һәм тән газапларын тыныч кичерергә тырыша. Бу көчсезлекме әллә?! Юк, сабырлык күп көч таләп итә.

"Сабыр" сүзе безгә гарәп теленнән кергән. Ул сабырлыктан кала, "саклау, тотып тору, бикләү" дигәнне дә аңлата. Кеше үзен ачудан, башкаларның халәтен боза алган начар хисләрдән, начар нәтиҗәгә китергән теләкләрдән саклый - мәсәлән, хәмер эчемлекләр куллану теләгеннән. Кешенең сабырлык кебек күркәм сыйфатын борынгы һәм хәзерге заман шагыйрь-язучылары да үзләренең әсәрләрендә үрнәк итеп тасвирлыйлар.

Сабырлык - һәр мөселман кешесенә хас булырга тиешле сыйфат. Бу сыйфаты булган кеше көнен, атнасын, гомумән, тормышын дөрес планлаштырып үз максатына ирешә. Сабырсызлык исә, киресенчә, кире нәтиҗәләргә китерә. Чөнки еш кына кайберәүләр сабырлыклары җитмәү сәбәпле башлаган эшләрен ташлыйлар.




Коръәндәге сүзләр мөселман кешесенә сабырлыкның бу дөнья һәм ахирәт өчен әһәмиятен күрсәтә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Менә шулар Аллаһның рәхмәтенә һәм Аның ярлыкавына лаектыр. Тугры юлны тапканнар да шулар булыр" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 157 нче аяте).

"(Ий, Рәсүлем), әйт син:

- Иманлы кешеләр! Раббыгыздан куркыгыз. Бу дөньяда игелек кылганнар өчен (җәннәтләр) нигъмәтләр бар. Аллаһның җирләре бик киңдер. Бары тик сабыр иткәннәргә генә бихисап әҗерләр булачак" ("Зүмәра (Халык өере)" сүрәсенең 10 нчы аяте).

## МӘЧЕТ ӘДӘПЛӘРЕ

**Аллаһы Тәгалә "Нур" сүрәсенең 36-37 нче аятьләрендә: "Бу нурлы кандил байтак кына өйләрнең эчен яктырта. Шундый өйләрнең абруе артсын дип вә анда Үзенең исемен зекер итсеннәр өчен (Аллаһ) рөхсәт бирде. Ул өйләрдә иртә-кич Аңа тәсбих әйтәләр (Аллаһка мәдех укыйлар). Бар шундый кешеләр, аларны сәүдә һәм алыш-биреш эшләре дә Аллаһны зекер итүдән, (вакытында) намаз укудан, зәкят бирүдән аера алмый. Алар дәһшәтле Көн килеп, йөрәкләрне тетрәтә торган, күзләрне акайта торган Көннән куркалар", - ди. (Монда һәм алга таба аятьләр "Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре" китабыннан алып бирелә.) Бу аятьтә Аллаһ Раббыбыз мәчетләрнең нигә кирәклеген, ни өчен төзелгәнлеген ачык итеп аңлатып бирә.**



Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән:

"Кешеләр мәчетләр белән мактанышa башлаганчы Кыямәт купмас". Мәчетләрнең зурлыгы, матурлыгы, байлыгы, манараларының биеклеге һәм башка шуның ише әйберләр белән мактанышу бүгенге көндә мөселманнар арасында киң таралган һәм бу - Пәйгамбәребез (сгв) әйткәнчә, Кыямәт якынлашуның билгесе. Мондый мактанышулар Аллаһның хак дине булган ислам диненә каршы килә, чөнки мәчетләр - Аллаһка гыйбадәт кылу өчен генә билгеләнгән йортлар.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән:

"Мәчетләрегезне сабыйлардан, диваналардан, сату-алу эшләреннән, низаг-талашлардан, тавыш күтәрүдән саклагыз". Пәйгамбәребез (сгв) мәчетләрнең пычрануына яки Аллаһны искә алудан башка тавышларның чыгуына китерә торган сәбәпләрне мәчетләрдән ерак тотарга куша.

Пәйгамбәребез (сгв) дә мәчетләрнең ни өчен төзелгәнен аңлаткан:

"Мәчетләр Аллаһны зекер итәр өчен һәм намаз укыр өчен генә төзелде". Мәчетләр никах уку, балага исем кушу яисә мәеткә җеназа уку өчен каралмаган. Нәсара динендә булучылар гына бу мәрасимнәрне чиркәүләрдә үти, ә безне Пәйгамбәребез (сгв) аларга охшаудан тыйган.

Имам Бохари бер кыйссаны риваять кыла. Язид Әл-Кинди сөйләгән: "Гомәр ибен Әл-Хаттаб миңа: "Теге икәүне китер әле", - диде һәм мин ул әйткән ике кешене китердем. Алар: "Сез кем?" - дип сорадылар һәм үзләренең Таиф шәһәреннән булуларын әйттеләр. Гомәр әйтте: "Әгәр Мәдинә әһелләреннән булсагыз, сезгә җәза бирер идем, Аллаһның илчесе мәчетендә нигә тавышыгызны күтәрәсез? Кайда икәнегезне беләсезме сез?!" Ягъни, Гомәр хәлифә булган вакытта, тавышланырга ярамый икәнен белеп тә, мәчеттә тавышланган кешегә суктырып җәза бирү каралган булган.

Мөселман кешесе мәчеткә кергәндә үк Пәйгамбәребез (сгв) өйрәткән догаларны укып керергә тиеш:

"Әй Аллаһ, миңа рәхмәт ишекләреңне ач". Һәм мәчеттән чыкканда да дога укып чыгарга тиеш:

"Әй Аллаһ, миңа фазыләт ишекләреңне ач".

Алда китерелгән аятьтәге "...Аның исеме зекер ителә..." дигән сүзләрне Ибен Габбас: "Аллаһның Китабы Коръән укыла", - дип аңлаткан.

"Әгъраф (Пәрдә, калкулык)" сүрәсенең 204 нче аятендә Аллаһы Тәгалә: "Коръән укылганда шауламыйча тыңлагыз: сез Аллаһның ярлыкавына юлыгырсыз", - ди. Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә на-

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### КАМИЛ ХӘЗРӘТ БӨЕКБРИТАНИЯНЕҢ РОССИЯДӘГЕ ИЛЧЕСЕ УРЫНБАСАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

**12 март көнне Татарстан мөфтие вазифаларын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллин Бөекбританиянең Россиядәге Илчесе урынбасары Денис Киф белән очрашты.**

Алар төрле диннәр арасындагы диалог һәм толерантлык турында сөйләште. Камил хәзрәт Татарстанда христиан һәм ислам динен тотучыларның үзара килешеп яшәве Татарстанны һәрвакыт башкалардан аерып торуын җиткерде.

Денис Киф, үз чиратында, бу үзенчәлекнең Бөекбританиядәге дини вазгыятькә дә хас булуы хакында әйтте. Исламның Англиядә үсеш алуын, ә Лондонда мөселманнар күпләп яшәгән районнар барлыгын ассызыклады.

Очрашу ахырында ике як та алга таба хезмәттәшлек итү турында теләкләрен җиткерде.

### ДИНИ БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕНӘ КАГЫЛЫШЛЫ СӨЙЛӘШҮ УЗДЫ

**13 март көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә "Татарстанда һөнәри дини белем бирү дәрәҗәләре" дип аталган темага "түгәрәк өстәл" узды.**

Чарада мөфтиятнең Голәмалар шурасы рәисе Рөстәм хәзрәт Батыр, Татарстан Фәннәр академиясенең Исламият үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Камил Насыйбуллов, Россия ислам институтының уку-укыту эшләре буенча проректоры Марат Гыйльманов, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Айдар Карибуллин, Россия ислам институтының уку-укыту бүлеге җитәкчесе Нәзирә Гыйззәтуллина, мөселман уку йортлары җитәкчеләре катнашты.

К.Насыйбуллов "Татарстан мөселман дини уку йортлары буенча мониторинг: гомуми нәтиҗәләр һәм киңәшләр" дип аталган темага чыгыш ясады. 2012 елда Исламият үзәге Голәмалар шурасы, шулай ук нәзарәтнең уку-укыту бүлеге белән берлектә дини уку йортларындагы проблемаларны өйрәнгән иде. Камил әфәнде шуның нәтиҗәләре белән таныштырды.

М.Гыйльманов "Татарстанда югары һөнәри дини белем: үткәне һәм алгарышлары" дип аталган темага чыгыш ясады. Н.Гыйззәтуллина исә дини уку йортларының уку-укыту планнарындагы үзенчәлекләр турында сөйләде.

"Түгәрәк өстәл" сөйләшүендә А.Карибуллин Татарстан мәдрәсәләренә уку-укыту технологияләрен кертү мәсьәләсен күтәрде.

Катнашучылар һөнәри дини уку йортларының Уку-укыту методик берлеген булдырырга кирәк дигән фикергә килде.

### МӨХТӘСИБӘТ СПОРТ ЯРЫШЫ ҮТКӘРДЕ

**10 март көнне Югары Ослан Җәмигъ мәчете мәхәлләсендә яшь мөселманнар арасында өстәл теннисы буенча ярыш үткәрелде.** Спорт чарасын Югары Ослан районы мөхтәсибәте оештырды.

***Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# ГАТАУЛЛА БАЯЗИТОВ –

## Россия җәмәгатьчелегенә ислам асылын җиткерүче татар зыялысы



**XVIII гасыр ахыры - XIX гасыр башында татар җәмгыятендә зур үзгәрешләр була. Әлеге үзгәрешләр рухи өлкәдә дә күзәтелә. Татар укымышлылары халыкның дини белем-мәгърифәт өлкәсендәге бөтен мәнфәгатьләрен чишәр өчен тырыша башлый. Халыкның белемен күтәрү максатында алар армый-талмый укыталар, дини хезмәтләр язалар, милли газет-журналлар чыгару өчен рөхсәт алырга омтылыш ясыйлар. Әлеге изге-игелекле эшнең башында Габденнасыйр Курсави, Габдеррәхим Утыз Имәни әл-Болгари, Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани һәм башкалар тора. Бу исемлекне совет власте вакытында сызып ташланган шәхесләр белән тулыландыру мөмкин. Шундый шәхесләрнең берсе - дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист, нәшир Гатаулла Баязитов.**

Гатаулла Баязитов 1847 елда Рязань губернасының Касыйм өязендәге Төмәнсу (Темников) авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне шул авылда этисе мәдрәсәсендә ала. Аннары укуын Касыйм шәһәреннән ерак булмаган Чутай авылындагы Байморат мәдрәсәсендә дәвам итә. Берничә елдан күпләргә билгеле булган Кышкар мәдрәсәсенә күчә. Казан артында урнашкан әлеге мәдрәсә (хәзер Татарстанның Арча районына карый) Г.Баязитовның үзаңы, дөньяга карашы формалашуына зур өлеш кертә. Моның нәтиҗәсендә ул татарларның дини тормышында реформалар башлаучыларның берсенә әйләнә.

Чутай авылына килеп урнашканнан соң, Гатаулла хәзрәт биредә фәлсәфә һәм логика укыта. Ләкин биредә озак эшләми, чөнки 1871 елда Петербургтан Икенче мөселман мәхәлләсен җитәкләргә чакыру ала һәм ризалаша. Г.Баязитов башкаланың иҗтимагый тормышына актив кереп китә, моның өчен урыс телен өйрәнә һәм шәһәрнең дәрәҗәле кешеләре белән аралаша. Бераз вакыт үткәннән соң, ул Балтыйк флотының хәрби ахун дәрәҗәсен ала. Ул вакытта хәрби хезмәттә, дини кешеләргә хөрмәт йөзеннән, дини йолаларны үтәү өчен мөмкинлекләр тудырыла, чөнки дин тотучы мөселманнар гадел, эш сөючән, аек булулары белән аерылып тора. Петербург хәрби гарнизонында мөәзин, мулла, ахун кебек хезмәт вазифалары була. Әлбәттә, хәрби ахун булу өчен зур белемгә һәм аерым бер әхлакый сыйфатларга ия булу сорала. Ул вакытта, сайлау аша үтеп, иң лаеклысы гына бу дәрәҗәгә ирешә ала торган була. Гатаулла Баязитовның шушы дәрәҗәле урынга сайлануы аның чынлап та бик белемле һәм Петербург мөселманнары арасында дәрәҗәле, абруйлы булуын ачык күрсәтә.

Мөселманнарның төрле өлкәләрдә актив эшчәнлек алып баруның мөһимлеген яхшы аңлап, Г.Баязитов милли һәм дини рухтагы урыс һәм татар телендә газет-журналлар чыгарырга хыяллана. Аңа кадәр бу өлкәдә рөхсәт алу өчен мөрәҗәгать итүләр күп булса да, уңай җавап алынмаган була әле. Г.Баязитов 1880 нче елларда урыс һәм татар телендә "Хәфтә" ("Атна") исемле газет чыгару өчен рөхсәт алырга теләп мөрәҗәгать итә. Ләкин аның мөрәҗәгате дә озак еллар дәвамында җавапсыз кала. Бары тик 1905 елда гына ул "Нур" исемле газет чыгарырга рөхсәт ала, соңыннан аның нәшире һәм редакторы була. Шулай итеп, Россиядә беренче татар газеты нәшер ителә башлый. Әлеге басма битләрендә шул заманга хас бик күп актуаль мәсьәләләр күтәрелә, ләкин үзенең төп максатын мөхәррир татарларның дини-әхлакый тәрбиясенә мөмкинлектән чыгып өлеш кертүдә күрә.

Петербургта яшәгән татарларны берләштерү максатын куеп, Г.Баязитов татар телендә булган газет чыгарудан тыш, татар мөселманнары өчен рухи үзәк тә кирәк булуын аңлый һәм 1881 елда Җәмигъ мәчете төзергә рөхсәт сорап, хакимияткә мөрәҗәгать итә. Ул вакытта Петербургта татарлар саны өч меңнән артык була. Шушы мәчет төзелешенә акча җыю бөтен Россия мөселманнарының бердәм җәмгыяви хәрәкәте кузгалуына сәбәп була, чөнки Россиянең шактый күп төбәкләреннән төзелеш фондына ярдәм килә башлый.

Дин галиме буларак, Гатаулла хәзрәт Баязитов төрле дини дәреслекләр яза, ислам тәгълиматына багышланган берничә җитди китапның авторы була. Урыс телендә дә басылып чыгу сәбәпле, алар Россия күләмендә зур кызыксыну уята, илдә яшәүче урыс телле мөселманнарга һәм, гомумән, халыкка ислам дине асылы турында акыллы, саллы фикерләр ишетергә мөмкинлек тудыра. Г.Баязитовның шушы хезмәтләре бик тә уңай бәяләнә. Соңрак исә бу китаплар төрек һәм француз телләренә дә тәрҗемә ителә. Шул вакытта татар галимнәре, гадәттә, гарәп телендә генә язалар һәм аларның хезмәтләрен Россиядә татар-мөселман халкы гына укый ала. Урыс һәм француз телендә ислам турында дәреслекләр чыгу исә башка милләтләрнең дә ислам дине белән таныша алу мөмкинлеген тудыра. Шушы хезмәтләре белән Г.Баязитов җәмгыятьтә ислам турында таралган хаталы фикерләрне дә дөресләргә омтыла. Чынлап та, бу хезмәтләр ул вакытта күпләр өчен ачыш буларак кабул ителә.

Хәзрәтнең Россиядә һәм чит илдә зур кызыксыну уяткан беренче китабы - "Ислам һәм фән". Ул Эрнст Ренан дигән француз тарихчысы һәм язучысының ислам һәм фән бер-берсенә каршы килә торган өлкәләр дип әйтүенә нигезле тәнкыйть була. Бу тема шулай ук "Ислам һәм прогресс" исемле хезмәтендә дә чагыла, биредә автор ислам дине фән үсешенә каршы түгел, ә киресенчә фәнне өйрәнергә, үстерергә өнди икәнен белдерә.

"Исламның фәнгә һәм башка дин кешеләренә мөнәсәбәте" дип исемләнгән хезмәтендә Баязитов толерантлык, ягъни башка диннәргә түземлелек хисе исламның төп принципларыннан берсе булуын дәлилли. Биредә автор ислам дине башка дин кешеләренә яхшы мөнәсәбәттә булуын һәм төрле дин әһелләре бер илдә, бер җирлектә бергәләп тыныч, тату яши алуларын ачып бирә.

Без дә бүген Гатаулла хәзрәт Баязитовның шушы юлын дәвам итеп, ислам дине артка, аска өстерәүче түгеллеген, ә киресенчә элек тә, хәзер дә фән, цивилизация үсешенә өндәүче һәм кешенең мәңгелек ахирәт тормышында гына түгел, ә бу дөньяда да бәхеткә, күркәм тормышка илтүче һәм ярдәм итүче бер тәгълимат булуын сүзебез, хезмәтебез, гамәлебез белән исбатлап күрсәтү - олуг бурычыбыз икәнлеген белергә тиешбез.

***Нәзир РӘХИМҖАНОВ,***
***Кукмара мәдрәсәсенең II курс шәкерте***

# МӘЧЕТ ӘДӘПЛӘРЕ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

маздагы Коръән уку яки намаздан тыш уку дип, ишетсәң яки ишетмәсәң дип аермый, ә гомумән әйтә. Шулай булгач, мәчеттә Коръән намаз вакытында укылса да, намаздан тыш укылса да аны тыңлау һәм шым тору вәҗип була. Гыйбадәттән башка эшләр белән шөгыльләнү, сөйләшеп утыру, хәтта сөйләшмичә тик торып та Коръәнне тыңламау - Аллаһы Тәгаләнең әмеренә каршы килү дигән сүз.

"Әгъраф (Пәрдә, калкулык) сүрәсенең 29 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә болай ди: "Әйт:

- Раббым гадел булырга боерды, - диген.

- Һәр сәҗдәдә йөзегезне Кыйблага таба юнәлтегез. Аллаһка ялварып, динне Аллаһ ризалыгы өчен (Аллаһ кабул итәрдәй) ихлас тотыгыз. Ул сезне әүвәл ничек яралткан булса, шулай ук Аның хозурына кайтачаксыз". Ягъни һәр мәчет Аллаһның йорты һәм һәр мәчеттә намаз уку тиешле. "Бу мәчеткә бармагыз, теге мәчеткә барыгыз", - дип әйтүчеләр Аллаһы Тәгаләнең алда әйтелгән сүзләренә каршы киләләр. Аллаһы Тәгалә тигез кылган әйберне Аллаһтан өстен булып ничек аермак мөмкин?!

"Әгъраф (Пәрдә, калкулык)" сүрәсенең 31 нче аятендә Аллаһы Тәгалә: "Әй, Адәм балалары, намаз укый торган урынга барганда һәрвакыт пакь киемнәр киегез; ашагыз, эчегез, ләкин (артыгын) исраф кылмагыз. Аллаһ исрафчыларны сөйми", - ди. Ягъни, мөшрикләрнең Кәгъбәне шәрә килеш таваф кылуларыннан аермалы буларак, Аллаһы Тәгалә мәчеткә барганда гаурәтләрне капларга һәм иң яхшы киемнәрне кияргә куша. Ир-атларга исә ислемайлар сөртү, сөрмә тарту, тешне тазарту, чиста-пакь ак киемнәр кию мөстәхәб булып тора (бигрәк тә җомга һәм гает көннәрендә).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән:

"Киемнәрегездән агын киегез, чөнки ул - киемнәрегезнең иң хәерлесе".

"Әнфәл (Табыш малы)" сүрәсенең 35 нче аятендә Аллаһы Тәгалә болай ди: "Аларның Бәйтулла янындагы догалары да сызгыру яки кул чәбәкләүдән башка нәрсә түгел. (Әй, кяферләр) инкарь итүегезгә күрә, хәзер инде газабын да татыгыз. (Риваятьләргә күрә, мөшрикләрнең кайбер ирләре, хатыннары Бәйтулла тирәли ялангач килеш әйләнеп йөри, таваф итә. Таваф вакытында алар бармакларын авызларына кабып сызгыралар, кул чабалар. Баксаң, бу аларның дога кылуы икән.)" Төрле тавышлар чыгару, кычкырулар мөшрикләрнең гадәтләреннән, гыйбадәтләреннән санала. Мондый эшләр мәчетләрдә тыела.

"Тәүбә" сүрәсенең 17-18 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә: "Аллаһтан башка тәңре эзләүчеләр үзләренең кяфер булганлыгына үзләре шаһитлек иткәнгә күрә, Аллаһның йорты - мәчетне торгызырга йөрүләре файдалы эш булачак түгел. Менә шулай! Аларның бөтен бу эшләре заяга китәр. Һәм алар ут эчендә дәвамлы калачак. Аллаһка иман китергәннәр, Ахирәт көненә инанганнар, намаз калдырмаганнар, зәкят биргәннәр вә Аллаһтан башка берәүдән дә курыкмаганнар гына мәчет кордырырга тиеш. Аларның тугры юлда булачагына өмет бар", - дип мөрәҗәгать итә. Ягъни алар үзләре үк үзләренең мөшрик булуларына "мин нәсара", "мин яһүди" яки "мин мөшрик" дип шаһитлек бирәләр. Мәчетләрне чын тергезүчеләр булып, аны төзүчеләрдән дә бигрәк, бер Аллаһка гына ихлас күңелдән гыйбадәт кылып мәчеткә йөрүчеләр тора.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйтә:

"Әгәр бер кешенең мәчеткә даими йөрүен күрсәгез, аның иманлы булуына шаһитлек бирегез".

Шулай ук Пәйгамбәребез (сгв) әйткән:

"Әгәр Аллаһы Тәгалә бер кавемгә чир җибәрергә теләсә, мәчет әһелләренә карар һәм ул бәлане кире кайтарыр".

Мәчетләр булу, ягъни Аллаһка гыйбадәт кылу белән тергезелгән мәчетләр сәбәпле күп бәлаләр китә (үле мәчетләр сәбәпле түгел).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән:

"Сарыкларның бүресе булган кебек үк, шайтан - кешенең бүресе, бүре аерылган һәм читтә йөргән сарыкларны ала. Берүк, аерылудан сак булыгыз, җәмәгать белән, күпчелек белән һәм мәчетләр белән бергә булыгыз!" Һәм хәзерге заманда да күрәбез, мөселманнар арасында таралган фиркаләр һәм секталар мәчетләрдә түгел, ә мәчетләрдән тыш җирләрдә җыелалар, андый җирләргә барудан сак булыгыз, чөнки Пәйгамбәребез (сгв) безне бу турыда кисәтте.

Аллаһы Тәгалә "Җен" сүрәсенең 18 нче аятендә: "Барча мәчетләр бары тик Аллаһка гыйбадәт кылу урыны. Шуңа күрә, сез Аллаһка тиң дип, һичбер башка затка табынмагыз", - ди.

Сәхабәләр әйткәннәр:

"Мәчетләр - Аллаһның җирдәге йортлары. Мәчеткә үзен зиярат кылырга килүчене Аллаһ, әлбәттә, хөрмәт кылыр". Ягъни мәчеткә йөрүчеләргә Аллаһы Тәгалә Үзенең дөнья вә ахирәт нигъмәтләрен бирер.

Мәчетләрдә кешене иза кылу, рәнҗетү ярамый. Башка кешегә намаз укырга комачауларлык итеп пышылдап сөйләшү дә тыела.

Кеше йортына керсәк, үзебезне ничек яхшы итеп тотарга тырышабыз! Ә галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһ йортларына керсәк, без үзебезне ничек тотарга тиеш соң?! Әлбәттә, күпкә әдәплерәк, тыйнаграк һәм бөек Аллаһ каршында мескен бәндә икәнебезне тоеп.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән: "Җир йөзендә Аллаһка иң сөекле урыннар - мәчетләр, иң сөйкемсез урыннар - базарлар". Аллаһ ризалыгына ирешәсебез килсә, Аллаһка сөекле урында мөмкин кадәр күбрәк булуыбыз тиешле түгелме?!

Аллаһка гыйбадәт кылып, мәчетләрдә вакытларыбызны күбрәк итеп үткәрүләр насыйп булса иде!

**Рафикъ хәзрәт МИҢНӘХМӘТОВ,**
**Татарстанның көнчыгыш төбәге казые,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең**
**Голамалар шурасы әгъзасы,**
**Әлмәт районы имам-мөхтәсибе**

# ИМАМ ҺӘМ МӨДӘРРИС СӘРВӘРЕТДИН БИНЕ МИФТАХЕТДИН

**Халкыбызның рухи мирасы әлегә барланып бетүдән бик ерак. Архивларда, китапханәләрдә кул тими ята торган борынгы кулъязмалардан, иске китап, газет һәм журнал битләреннән эзләп табып, милләтебезгә кайтарасы бихисап галимнәребез, руханиларыбыз, зыялы шәхесләребез бар. Болар - үзләре яшәгән чор тарихының мөһим сыйфатларын җыйнап, үз күңелләренә сыйдырып, буыннан-буынга тапшыру сәләтенә ия булган остазлар, акыл ияләре. Аларның эшчәнлеген, иҗатын өйрәнү һәм җәмәгатьчелеккә таныту өчен махсус хәзерлеге һәм иң әһәмиятлесе, бу эш белән шөгыльләнергә теләге булган яшь буын галимнәргә бүген ихтыяҗ гаять зур.**




Бу язмада шундый өйрәнелми килә торган руханиларыбызның берсенә - имам һәм мөдәррис Сәрвәретдин бине Мифтахетдин шәхесенә тукталып, белгечләрнең һәм киң катлау укучыларның игътибарын җәлеп итәсебез килә. 2012 елда аның тууына 150 ел тулды, әмма, ни кызганыч, XX гасыр башында берничә китап язып бастырган, даими рәвештә Ризаэтдин Фәхретдин чыгарган "Шура" журналында язышкан бу автор турында бүгенге көнгә кадәр татар җәмәгатьчелегенең мәгълүматы юк, хезмәтләре дә һаман әйләнешкә кереп китә алмый. Бабасының мирасын танытыр өчен җан аткан оныгы - математика буенча дөньякүләм танылган галим, физика-математика фәннәре докторы, Мәскәү дәүләт университеты профессоры Ижат Хак улы Сабитов фикеренчә, Сәрвәретдин бине Мифтахетдин - үз заманының күренекле укымышлысы дип аталырга тулы хокукка ия шәхес (Иджад Сабитов. Мечтаю вернуть имя деда // Татарские новости. - 2009. - № 3-4). Шәехзадә Бабич аның турында үзенең "Китаб-ен-нас фи хакк-әл-хавас" ("Күренекле шәхесләр турында китап") исемле атаклы әсәрендә хәтта аерым эпиграмма да язып калдырган:

***Сәрвәретдин Мифтахетдин -  һәм мөдәррис, һәм имам,***
***Ул тугандык "ислам, ислам, ислам, ислам..."  дип туган!***

Х?зерге көннәргә килеп җиткән хезмәтләре буенча без аны олылап, хәзрәт дип атый алабыз. Оныгының тырышлыгы белән Сәрвәретдин хәзрәтнең исеме "Татар энциклопедиясе"нә кертелде һәм русча басылган V томда (Казан, 2011) аның турында түбәндәге мәгълүмат урын алды:

Дин эшлеклесе һәм мәгърифәтче Сабитов Сәрвәретдин Мифтахетдин улы 1862 елда Казан губернасы Чистай өязендә (кайбер чыганаклар буенча, Самара губернасы Бөгелмә өязендә) туган. Троицк мәдрәсәсендә белем алган, 1890-1913 елларда Оренбург өязенең Бушман-Суун-Каракыпчак волостеның Теләумбәт авылында имам-хатыйп һәм мөдәррис булып торган, 1913 елдан Оренбург өязе Югары Биккүз авылында яшәгән. Ысулы җәдит мәктәпләрен оештыру белән шөгыльләнгән. Ислам дине белеме, педагогика буенча хезмәтләре бар: Вәзаифе инсан. - Казан, 1898; Әдәбе тәзәввүҗ. - Оренбург, 1908;  Ислам. Тәрәккый. Ислах. - Казан, 1913.

"Татар энциклопедиясе"нә кадәр үк, тарих фәннәре кандидаты Денис Денисов Уфа, Оренбург архивларыннан Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең тормыш юлы белән бәйле кайбер документлар табып, "Уралда ислам" энциклопедиясендә (2009) беренче булып аның хакында аерым бер матдә бастырган иде (Ислам на Урале. Энциклопедический словарь. Серия "Ислам в Российской Федерации". Выпуск V. - Москва - Нижний Новгород, ИД "Медина", 2009. - С. 324). Анда Сәрвәретдин хәзрәтнең Төркиядә белем алуы, 1907 елда Бушман-Суун-Каракыпчак волостеның мөселман җәмгыятен төзүдә башлап йөрүе һәм аның рәисе булуы, актив рәвештә җәдитчелек идеяләрен, аеруча мәдрәсәләрдә рус телен һәм дөньяви фәннәр укытуны яклавы, шуның аркасында кадимчеләрнең яла ягуларына дучар булуы, бай китапханә туплавы һ. б. мәгълүматлар хәбәр ителә. Вафат булу тарихы 1916 елдан соң дип әйтелә. Д.Н. Денисов хәзерләгән белешмә бүгенге көндә Сабитов Сәрвәретдин Мифтахетдин улының тәрҗемәи хәле буенча иң тулы чыганак булып тора, ләкин, кызганыч, монда да сораулар җаваплардан күбрәк, бу өлкәдә әле эзләнәсе дә эзләнәсе.

Нигездә, Сәрвәретдин хәзрәтнең китапларының саны җиде-сигез булып (бу мәкаләнең ахырында аның басылган хезмәтләренең библиографиясе бирелә), аларны Казан һәм Мәскәү китапханәләреннән табу бик кыен түгел. Кыен булганы - авторның телен һәм әйтергә теләгән фикерен ачык аңлау мәсьәләсе, чөнки Сәрвәретдин бине Мифтахетдин XX гасыр башы сөйләм теленнән аермалы буларак, шактый күп гарәп һәм фарсы сүзләрен кулланып, гаять катлаулы дини-фәлсәфи темаларга язган. Әсәрләрен өстән генә карап чыкканда да, аның ислам фәлсәфәсе, дин социологиясе буенча тирән фикер йөрткәнлеген күреп була. Ләкин бүгенге көндә дә бу фәннәр буенча татарча атамалар (терминнар) эшләнмәгәнлеген һәм саф татар телендә гыйльми хезмәтләр язылмаганлыгын искә алсак, нигә һаман Сәрвәретдин хәзрәт әсәрләренә галимнәрнең кулы тимәгәнлеген фаразларга була: теле авыр, темасы катлаулы, атамалар аңлашылмый. Шул ук вакытта Сәрвәретдин хәзрәт кулланган фәнни тел, нигездә, аның белән бер чорда яшәгән дин галимнәре Муса Бигиев, Зыя Камалиларның теленнән әллә ни авыр түгел, дип әйтергә мөмкин.

"Шура" журналында басылган мәкаләләре буенча гына фикер йөртсәк тә, Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең берничә зур күләмле язмасында Аллаһның берлегенә нигезләнгән тәүхид темасын күпьяклап эшләгәнен күрәбез, шулай ук галим үз заманы фәннәренең ислам дине белән мөнәсәбәтен, диндә тәкълит (иярүчәнлекнең) урынын, исламдагы әхлак мәсьәләләрен яктырта, европалылар күзлегеннән чыгып караганда мөселманнарның тормышы ничек күренгәнлеген анализлый. Мәкаләләрнең күпчелегендә тәнкыйди караш өстенлек итә: язучы ислам әһелләре арасындагы торгынлыкны, мөселман дөньясының Европадан артта калу сәбәпләрен эзләгәндә христиан миссионерларын гына сүгеп калмый, мөселманнарның үзләрендә дә кимчелекләр күп булуын әйтә. Мәсәлән, "Шура" журналының 1911 елның 13 нче санында чыккан "Исламның хәле хазирәсе вә бүгенге мөселманнар" мәкаләсеннән бер өзек китереп, авторның тел-өслүп үзенчәлекләренә һәм фикер сөрешенә игътибар бирик:

- Әгәр дә хәзрәти пәйгамбәр шимдики (хәзерге) заманда каберендән кайтып, шимдики өммәтләренә нәзар кыйлса (караса) иде: "Бунлар бәнем өммәтем дәгел (түгел)," - дия белгел (дия алыр), анлардан фырар идәр (качар) иде. Чөнки хәзерге өммәтләренең гамәлләре, хәрәкәтләре исламиятнең асыл мәүзугы (темасы) вә кавагыйде мөкәтдәсенә (изге кагыйдәләренә) бигрәк хилаф (хата) улынмактадыр, - дип сүз башлый автор. Үз заманы гыйлемнәренең хыялдан гына гыйбарәт булуын, мөселманнарның тәрбиясенә һәм үсешенә файда китермәвен әйтеп, автор, бу гыйлемнәрнең чын дини тәгълиматтан һәм Коръән хакыйкатеннән тулысынча ерак калуын тәнкыйть итә. Үз чоры галимнәренең: "Нәфак (шом һәм дошманлык тудыру), ... рия (икейөзлелек) вә мөдаһнә (ялагайлык), хөсед (көнчелек) вә гайбәт, бөһтан (яла ягу) вә ифтира (нахак сөйләү) кеби зөмаим (начарлык) илә мөтассав (тулган) иделдекләре күрелер", - ди (389 б.).

Үз дәвере суфилары һәм тарикатьләр (суфи оешмалар) турында Сәрвәретдин хәзрәт болай ди: "Хәлбуки хәзерге голамәмез илә шәйхләремез вә суфиларымыз бу көндә бөтен мөселманнарның мөкатдәсләре (изгеләре) вә юлбашчылары булып, бөтен галәме ислам аларның тәрбияләрендәдер. Боларның күбесе асыл исламиягә вә рәсуллаһның сөннәт рәшидәсенә муафикъ дәгел (туры килмәгән) кагыйдәләр илә мөселманнарны тәрбия кыладыр. Хәзерге тарикъләр вә кагыйдәләрне гакыл вә хикмәт узрә татбик идеп (чагыштырып, тикшереп) карасак, бу икенең арасында һич тә мөтабакат (охшашлык, туры килү) күренмәс. Аларның күбесе бидгать (исламга соңыннан кертелгән яңалык) вә дүзмәләрдән (уйдырма) гыйбарәт, әсас хакыйкатьдән хариҗдыр (читтә, тышта)", - ди. Европалыларның мөселманнарга кимсетеп каравына, мөселманнар үзләре дә гаепле, чөнки алар үз хокукларын белмиләр һәм якламыйлар, ди. Әлеге  фикер "Шура"да 1913-1914 елларда басылган "Ислам вә мөселманнар" исемле мәкаләдә дә дәвам иттерелә.

"Европалылар вә шимдики мөселманнар" ("Шура", 1911, № 14, 427-429 б.) исемле мәкаләсендә исә автор мөселманнарга һәм исламга дошманлык яки тәнкыйть күзе белән караучы европалыларны өч төркемгә бүлеп күрсәтә һәм һәрберсенә төпле бәяләмә бирә. Беренче төркемгә ул миссионерларны кертә: алар, христианнар белән мөселманнар арасындагы сәяси каршылык һәм көрәшләр тарихын гел истә тотып, үзара дошманлык хисен арттырып тору яклы, ди. Автор Шам, Мисыр, Әндалусиядә булган ислам-христиан бәрелешләрен, хәлифәлекнең Госманлы дәүләтенә күчкәннән соң булган дини юнәлешле сугышларны анализлап, христиан миссионерларның "төп максаты бу дөньядан әһле исламны юк итү" икәнлегенә басым ясый. Миссионерларны, кайчан да булса ислам дине өстен килер дә, мөселманнар бар дөньяга хуҗа булырлар дигән курку тойгысы биләгән. Шуңа күрә алар бар көчләренә мөселманнарны каралау, аларга яла ягу белән шөгыльләнәләр, ислам динен золым итеп күрсәтергә тырышалар, ди.

Икенче төркемгә "исламның хөкемнәрен аңламаган Ренан һәм башка Европа философлары" керә. Бу акыл ияләренә, автор фикеренчә, барлык диннәргә, хәтта христианлык, яһүди һәм ислам тәрбия ысулларына да түбәнсетеп карау хас. Болар исламга миссионерлардан да көчлерәк һөҗүм итәләр, аларның карашы буенча, исламның мәдәният белән бер бәйләнеше дә юк, бу дингә кыргый бер тәгълимат итеп карыйлар, ди. Сәрвәретдин хәзрәт өченче төркемгә материалистларны һәм рационалистларны аера. Болар бар нәрсәне акыл һәм мантыйк күзлегеннән генә тикшереп, фәнгә мөнәсәбәттә бәялиләр. Шуңа күрә ислам динендәге кайбер догмаларны кире кагалар, мәсәлән, Коръәндә әйтелгән җиһанның алты көндә яратылуы, Адәм галәйһиссәламнең җирдәге бар кешеләрнең атасы булуы, хатын-кызларның аның сөягеннән яратылуы, туфанда Нух пәйгамбәрнең тереклекне коткарып калуы һ. б. вакыйгалар физиология фәненә бөтенләй туры килми дип ассызыклыйлар, ди.

Сәрвәретдин бине Мифтахетдиннең "Шура" журналының 1908-1909 елгы саннарында урын алган зур күләмле "Тәүхид, хәят, ислам" мәкаләсе, 1898 елда басылган "Нәүгы бәшар" ("Кешелекнең яратылышы") китабы кебек үк, дөнья яратылышы, эволюциясе һәм киләчәге турында фәлсәфи уйлануларга нигезләнгән. Китабына язган кереш сүздә ул, хәзерге телгә күчереп әйткәндә, болай ди: "Барлык адәм балалары өстенә кешелеккә хас булган күркәм сыйфатларны тулы рәвештә саклап калу һәм бөтен тиешле вазифаларны Аллаһның хикмәте вә намус кушканча үтәү бурычы йөкләнгән. Һәрбер кешегә үзен һәм Хакыйкатьне танып белү, Аллаһның хикмәте белән бәйле намус кануны кушканча хәрәкәт итүе дә тиеш булганга, адәм балаларының күркәм сыйфатларын тасвирлауга багышланган кечкенә генә бер хезмәт яздым. Ватанпәрвәрлегемнең нәтиҗәсе булган бу хезмәтнең язылуы ватандашларым өчен бер үрнәк һәм аңлатма булуын гына телим".




Ун ел соңрак басылган мәкаләсендә дә автор әлеге максатны күздә тотып, адәм баласының дөньяга яратылган вакытыннан алып ия булган үзенчәлекләрен аңлата һәм аларның ни рәвешле үстерелә алуы турында сөйли. Аның фикеренчә, адәм баласының тормышы бер-берсе белән бәйле булган ике нәрсәгә нигезләнә: берсе - кешенең туганда ук үзенә бирелгән мөмкинлекләрен, сәләтен, теләкләрен күрә һәм бәяли белүе, икенчесе - гыйлем һәм мәгърифәт. Кешеләрнең күркәм сыйфатларын (фазиләтләрен) өч төргә бүлә: 1) Нәфес сыйфатлары (фазаиле нәфсия); 2) Тән (гәүдә) сыйфатлары (фәзаиле бәдәния); 3) Иҗтимагый сыйфатлар (фәзаиле иҗтимагыя). Бу сыйфатларның һәрбере язмада аерым-аерым аңлатыла һәм тәрбия нәтиҗәсендә үстерелә алу мөмкинлеге әйтелә. Алар арасында иң әһәмиятлесе итеп, Сәрвәретдин хәзрәт беренче төрне

(Ахыры 4 нче биттә.)

# ИМАМ ҺӘМ МӨДӘРРИС СӘРВӘРЕТДИН БИНЕ МИФТАХЕТДИН

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

күрсәтә, чөнки нәфес фазиләтләренең нигезен тәүхид һәм мәгърифәт тәшкил итә, тәһарәт, гыйбадәт, гадәләт, гыйффәт кебек әхлакый сыйфатлар тулыландыра, ди. Дин, яратылыш, кешенең яратылыштан ия булган үзенчәлекләре бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тора, гыйлем һәм мәгариф ярдәмендә тәрбия иткәндә кешенең акыл (акли) һәм дини гыйлемнәрдә зур мөмкинлекләргә ирешә алуы әйтелә.

Күргәнебезчә, мәкалә, дин социологиясе күзлегеннән чыгып, инсан тәрбиясе, рациональ һәм дини гыйлемнәр ярдәме белән кешенең җитлегү, үз-үзен үстерү мөмкинлеге һ. б. хакында укучыларга юл күрсәтүне максат итеп куя, дин аша гуманизм идеяләрен күтәрә. Галимнең аңлату ысулы, гарәпчә-фарсыча гыйбарәләрне һәм атамаларны еш куллануга карамастан, тәфсилле һәм эзлекле дип әйтергә кирәк.

Хәзрәтнең эшчәнлеген хронологик яктан күзәткәндә, үзе күтәргән катлаулы темаларга аның кабат-кабат әйләнеп кайтып эшләвен күрәбез. Мәсәлән, 1898 елда Казанда нәшер ителгән "Вәзаифе инсания" ("Кешенең вазифалары") китабындагы фикерләр соңрак "Шура"да басылган тирән эчтәлекле мәкаләләрендә дәвам иттерелә. Өйләнешү һәм гаилә этикасы темасына багышланган "Әдәбе тәзәввүҗ" (Өйләнешү әдәбе) (1908) һәм "Балалар тәрбиясе" (Эстәрлетамак, 1911) китаплары шәригать нигезенә корылган тәгълим-тәрбия, ягъни педагогика фәне буенча тәүге татарча дәреслекләр рәтендә санала ала. Изге китапның һәм гарәп теленең мөһим хосуслары турында язылган "Коръән газыйм" (Оренбург, 1903) һәм "Коръән шәриф" (Оренбург, 1911) исемле хезмәтләрендәге фикерләр "Шура" журналында 1912-1914 елларда басылган күләмле "Тәгъдиде әхвале инсан вә Коръән", "Хакыйкый ислам вә тәрбия" мәкаләләрендә дә дәвам ителә. Монда шуны да әйтергә кирәк, Сәрвәретдин бине Мифтахетдин Оренбургта Ризаэтдин Фәхретдин җитәкләгән "Шура" журналы белән актив эшчәнлеген бу басма рәсми рәвештә ябылганга кадәр алып бара: иң соңгы язмасы "Диннәр хакында нәзарият" 1917 елның 3-10 саннарында урын алган. Гомумән, "Шура" журналының библиографиясенә караганда, Сәрвәретдин бине Мифтахетдин дини темаларга иң күп мәкалә язучы авторлардан хисаплана ала. (Кара: Госманов М.Г., Мәрданов Р.Ф. "Шура" журналының библиографик күрсәткече. - Казан: Милли китап, 2000. Бу уңайдан Иҗат абый Сабитовның Миркасыйм Госманов турындагы җылы хатирәләрен дә искә аласы килә. Бабасы турында материал эзләп Казанга килгән вакытында ул Миркасыйм абыйга мөрәҗәгать итә һәм нәкъ менә М.Госманов аңа бабасының күпсанлы мәкаләләренең "Шура" журналында басылуын беренче тапкыр хәбәр итә, соңрак мәкаләләрнең исемлеген дә төзеп җибәрә (бу мәкалә ахырында китерелгән библиографиядә шул исемлектән файдаланылды). Галимнең әһәмиятле фикерләренең берсе мондый: "Ризаэтдин Фәхретдинов бик таләпчән кеше булган, Сәрвәретдин хәзрәтнең хезмәтләрен "Шура" журналында шулай күп санда бастырган икән, димәк, ул аларны югары бәяләгән".) XX гасыр башында чыккан башка журналларда да Сәрвәретдин хәзрәтнең язмалары булуы бик мөмкин.

Китаплары арасында махсус тукталып тикшерүөйрәнүне сорый торган "Ислам. Тәрәккый. Ислах" ("Ислам. Прогресс. Реформа") 1913 елда Казанда басылган һәм безгә билгеле булган соңгы китабы санала. Бу әсәрендә авторның бер бүлектә шул чорда хәлифәлек мәркәзе булган Төркиядә алып барылган мәгариф сәясәтенең дөрес булмавы хакында әйтелгән тәнкыйть фикерләре, госманлы империясенең тарихын һәм бүгенгесен яхшы белүе, гомумән, кулланган теленең дә госманлы теленә нык якын торуы Сәрвәретдин хәзрәтнең ниндидер бер сәбәп белән (мәсәлән, белем алу яки хаҗ юлында тукталу) чынлап та күпмедер вакыт Төркиядә яшәвенә ишарәли.

Әлбәттә, бу кечкенә язмабызда Сәрвәретдин бине Мифтахетдин иҗатының һәм фикер дөньясының төп хосусиятен ачып бетерүне максат итеп куймадык, киресенчә, без игътибар иткән үзенчәлекләр арасында бәлки иң кирәклесе әйтелми дә калгандыр әле дигән шөбһәбез юк түгел. Чөнки, инде югарыда да әйтелгәнчә, имам һәм мөдәррис Сәрвәретдин бине Мифтахетдин әсәрләрен аңлау һәм анализлау өчен шактый зур көч сарыф итәргә, махсус рәвештә җентекләп шөгыльләнергә кирәк. Тик шунысы шиксез ки, м?гъриф?тче һәм дин галиме булারак, ул тормышын үз халкына хезм?т итүг? багышлаган, әсәрләре белән җәмгыять әхлагын тазартырга, милләтенең дөньяга карашын киңәйтергә, рухи байлыгын, тән һәм җан сихәтлеген арттырырга омтылган. Әлбәттә, Мифтахетдин улы Сәрвәретдин Сабитов кебек зыялы милләт хадимнәребез татар рухи мирасы тарихында кирәгенчә бәяләнергә, онытылмаска, хөрмәт белән искә алынырга бик тә лаеклы.

Сәрвәретдин Мифтахетдин улы Сабитовның бүгенге көндә билгеле булган хезмәтләренең библиографиясе

1. Китаплары:

Вәзаифе инсания. Казан. 1898. Нәүгы бәшар. Казан, 1898. Коръән газыйм ниләр боера. Оренбург, 1903. (1908 елда тагын бер тапкыр басылган булса кирәк). Әдәбе тәзәввәс. Оренбург, 1908. Коръән шәриф. Оренбург, 1911. Балалар тәрбиясе. Эстәрлетамак, 1911. Ислам.Ислах.Тәрәккый. Казан, 1913.

2. "Шура" журналында басылган мәкаләләре:

Тәүхид. Хәят. Ислам. - 1908. № 11, 349-352 б.; № 12, 382-384 б.; № 14, 441-443 б.; № 15, 482-484 б.; № 18, 567-569 б.; № 21, 671-672 б.; № 23, 710-717 б.; 1909. № 2, 37-39 б.; № 4, 100-102 б.; № 5, 134-136 б.; № 7 197-200 б.

Тәүхид вә гыйлем. - 1909. № 19, 588-591 б.; № 22, 677-679 б.; № 24 740-742 б.; 1910. № 4, 102-103 б.; № 6, 164-165 б.; № 7, 195-196 б.; № 11, 324-327 б.; № 14, 419-421 б.; № 16, 484-485 б.; № 18, 549-550 б.; № 20, 612-614 б.; № 22, 675-676 б.; № 24, 740-741 б.

Диннәрнең тәхриф улындыгы ничек беленер. - 1911, № 12, 366-368 б.

Исламның хәле хазирәсе вә бүгенге мөселманнар. - 1911, № 13, 389-390 б.

Европалылар вә шимдики мөселманнар. - 1911, № 14, 427-429 б.

Тәкълит вә гыйлем. - 1911, № 17, 513-515 б.; № 18, 548-550 б.; № 19, 586-587 б.; № 21, 646-648 б.; № 22, 678-679 б.; № 23, 720-722 б.; 1912, № 1, 12-13 б.

Хикмәте лисаниядән бер нәбзә. - 1912, № 7, 196-200 б.

Тәгъдиде әхвале инсан вә Коръән. - 1912, № 16, 490-492 б.; № 17, 518-519 б.; № 18, 548-549 б.; № 19, 581-583 б.; № 20, 620-622 б.; № 22, 676-677 б.; 1913, № 7, 193-196 б.; № 9, 267-268 б.

Дине ислам вә өммәт. - 1913, № 7, 206-208 б.

Ислам вә мөселманнар. - 1913, № 18, 558 б.; № 19, 591-593 б.; № 20,623-625 б.; № 23, 714-715 б.; 1914, № 1, 8-11 б.; № 6, 177-178 б.; № 9, 260-262 б.; № 11, 324-325 б.; № 16, 496-497 б.; № 18, 550-553 б.

Хакыйкый ислам вә тәрбия. - 1914, № 13, 387-388 б.

Бөек галимнәр вә аларның гыйлем вә максатлары. - 1915, № 16, 501-502 б.; № 17, 532-534 б.; № 19, 591-592 б.; № 20, 628-630 б.; № 21, 661-663 б.; № 22, 692-695 б.; № 23, 716-718 б.

Диннәр хакында нәзарият. - 1917, № 3, 100-102 б.; № 6, 121-123 б.; № 7, 145-146 б.; № 8, 171-173 б.; № 9, 193-195 б.; № 10, 217-220 б.

**Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА,**
**филология фәннәре докторы,**
**Россия Фәннәр академиясенең Шәрыкны өйрәнү институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре**

# *Авылдашым, булдырасың!*

**Авылдашым, Мамадыш районы Уразбахты авылы егете Ильяс Халиков исеме республикабызга яхшы таныш. Мәктәптә укыганда ук районның данлыклы көрәшчесе иде ул. Мамадыш районының иң матур җиренә урнашкан Уразбахты авылында туган җырчы, галимебез белән без чын күңелдән горурланабыз. Авылның җиләкле таулары, инешләре, күлләре, матур табигате җырга-моңга сәләтне дә биргән. Авыл мәктәбендә укыганда ук Ильяс күп кенә концертларда катнаша, җырлар иҗат итә иде. Уразбахты мәктәбендә укыганда гаилә эстафетасында "Әссәламегаләйкем!" исемле җыр белән чыгыш ясап, укытучылар Ильясны җырлата башлаганнар.**



8 Март бәйрәменә райондашларына да олы бүләк ясады ул. Кече Кирмән, Көмешкүл авылларында, Мамадышның үзендә концерт карадык. Күптән түгел генә дөнья күргән "Мәчетләргә илтә сукмак" альбомыннан Коръәнгә, газиз әтиәнигә, гаиләгә, кан кардәшләргә, туган туфракка, җомга көненә, рамазан аена, Корбан гаетенә багышланган җырларын тыңлап хозурландык. Театральләштерелгән концерт-тәрбияви тамашадан карарга килүчеләр дөрес юнәлеш алганнар икән, димәк, җырчыбыз үз теләгенә ирешкән дигән сүз. Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында эшләүче "Мизгел" халык театры артистларына зур рәхмәтемне ирештерәсем килә. Алар да бик каты тырышкан. Моңа мисал булып, тамаша беткәч дә халыкның озак аерылышасы килмәү тора. Һәркемне мәңгелек уйландырды, калебләребезне җебетте. Кече Кирмән, Көмешкүл авылларындагы концертлардан кергән акчаларны тулаем авыл мәчетләренә, Мамадыштагысын өлешчә мәдрәсәгә бүләк итүен исәпкә алсак, алар чын күңелдән Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итүчеләр.

Бу уңышларга ирешүдә авылдашымның җәмәгате Нурфия ханымның да өлеше бик зур дип саныйм. Нурфия - әниемнең туган авылы Кукмара районы Бурсык-Елга авылыннан. Кунакка кайткач әнием янына керми китми. Җырларына көен авторбашкаручы үзе язса, шигырьләрен Нурфия ханым иҗат итә. Икесе дә укытучылар бит. "Тәрбиячеләр буларак, мөнәҗәтләр яшь буынны тәрбияләүдә, чисталык, пакьлек, яхшылыкны пропагандалауда көчле чара булып торганын аңлыйбыз. Бу - мөселман дәгъватының бер өлеше", - ди яшь пар. Аларның берсеннән-берсе гүзәл ике кызлары бар. Гаиләләре белән биш вакыт намазны калдырмыйлар. Кызлары да әти-әнисе белән бергә намаз укый.

Менә шундый күңелле мизгелләр киләчәк тормышларында да күп булса иде Халиковларның. Исән-сау, бәхетле, иманлы булыйк. Аллаһның ризалыгына ирешергә һәммәбезгә дә насыйп булсын!

**Фирая Мингалиева,**
**Мамадыш**

## Җөмәдиәләүвәл ае

**3 нче җөмәдиәләүвәлдә** Гомәр (рг) иман китереп, ислам динен кабул итә (ул вакытта барлыгы 40 мөселман була) һәм шул көнне Кәгъбәтуллаһ потлардан тазартылып, анда өйлә намазы укыла.

**8 нче җөмәдиәләүвәлдә** Гали (рг) Кәрамәллаһ вәҗүһә дөньяга килә.

**8 нче көнне** шулай ук хәзрәти Хәмзә белән Габбас, Аллаһка иман китереп, мөселман булалар.

**13 нче җөмәдиәләүвәл** - сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) иң яраткан кызы - Фатыйманың вафат булган көне.

***2013 елгы "Татар мөселман календаре"ннан***

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 10 (179) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35394.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 14 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanudан саклаңыгыз!**